■ Кыйсса

## ҺӘР ЗАТ АСЫЛЫНА ТАРТЫР

Бер шәһәрдә бер заһид бар иде. Аллаһы Тәгаләдән нәрсә теләсә - шул кабул булыр иде.

Беркөн бер кош тычкан баласы күтәреп бара иде. Көтмәгәндә тычкан җиргә егылып төште. Заһид дога кылды:

- И Бер Хода! Йә, бу тычканны кыз бала итеп бир, - диде.

Аллаһы Тәгалә шул заман аны кыз кылды. Ул кызны заһид тәрбияләп үстерде. Кыз балигъ булды, ягъни үсеп җитте исә, әйтте:

- Инде балигъ булдың, Әбүшакка (Әбүшак - тишек атасы, ягъни тычкан) кияүгә бирермен, - диде.

Кыз:

- Мине шундыйга бир: Галим булсын һәм аннан берәү дә көчле булмасын, - диде.

Заһид иң элек кояшка әйтте:

- Син көчле, кызымны кияүгә сиңа бирәм, - диде.

Кояш әйтте:

- Миннән көчле болыт бар, йөземне каплый, - диде.

Заһид болытка әйтте:

- Кызымны бирәм, - диде.

Болыт:

- Миннән көчле җил бар, - диде.

Заһид җилгә әйтте:

- Кызымны сиңа бирәм, - диде.

Җил:

- Тау миннән көчлерәк, мине туктата, - диде.

Заһид тауга әйтте:

- Әй Тау! Кызымны сиңа бирәм, - диде.

Тау:

- Миннән көчле тычкан бар, ул мине тишә, - диде.

Бу сүзләрне заһид кызына барып әйтте исә, кыз:

- Минем асылым тычкандыр, Әбүшак киявем булсын, - диде. Заһидтан сорады: - Аллаһы Тәгаләдән телә, мине тычкан кылсын, - диде.

Заһид дога кылды, кыз янә тычкан булды, Әбүшакка кияүгә чыкты.

**Һәрбер нәрсә асылына тартмый булмас икән.**

## ПАТША БУЛӘГЕ ҺӘМ АЛЛАҺЫҢ БИРГӘНЕ



Борынгы заманда ике гарип ярлы кеше бар иде. Берсе - яшь егет, берсе - карт, җәмәгать иясе иде. Бу яшь гарип һәр кичә вә көндез падишаһка изге догалар кылыр иде, падишаһтан бүләк өмет итәр иде. Ә карт гарип һәр кичә вә көндездә Аллаһы Тәгаләгә дога кылыр иде вә һәр морадын Аллаһы Тәгаләдән теләр иде.

Ул яшь егетнең падишаһка изге догалар кылганын барып әйттеләр:

- Фәлән мәхәлләдә бер яшь гарип бардыр, кичә вә көндез синең өчен хәер-догалар кыладыр, - диделәр.

Падишаһ аш пешерүчеләргә боерды:

- Хәлвә пешерегез! - диде.

Пешерделәр. Падишаһ янә боерды:

- Бер табакның төбенә йөз алтын салыгыз, аның өстенә хәлвә түшәгез, аннан соң фәлән мәхәлләдә торган яшь гарипкә илтеп бирегез, - диде. - Ә ул карт гарип Аллаһы Тәгаләдән сорый икән, аңа Алласы бирсен, - диде.

Шулай итеп, хәлвәне ул яшь гарипкә илтеп бирделәр. Яшь гарип хәлвәне туйганчы ашады, туйганнан соң табакның төбендә калганын табагы белән карт гарипкә бирде. Карт гарип калдык хәлвәне хатыны белән тәмам бетергәнче ашадылар. Беткәннән соң күрделәр: ул табак төбендә йөз алтын тәңкә килеп чыкты. Аны алдылар, байлыкка хуҗа булдылар.

Икенче көн яшь гарип тагын падишаһ өчен дога кылып, тагын сорарга кереште. Янә падишаһ янына барып әйттеләр:

- Шул фәлән яшь гарип янә сорыйдыр, - диделәр.

Падишаһ әйтте:

- Мин аңа йөз алтын тәңкә бирдем, аны кайда куйган? - диде.

Аннан соң бу яшь гариптән килеп сорадылар. Әйтте:

- Мин башта хәлвәне өстеннән туйганчы ашадым да калганын юлдашыма бирдем,- диде.

Падишаһка бу хәлдән хәбәр бирделәр, ул яшь гарипнең хәле шул рәвешчә булган, дип.


Падишаһ гаҗәпкә калды, тәүбәгә килде һәм әйтте:

- Бәндәнең бәндәгә биргәне һичнәрсә түгел икән, һәркемгә Аллаһы Тәгалә үзе бирсен, - диде.

Бу вакыйга шуның белән тәмам булды.

***"Мәҗмугыль-хикәят"тән алынды.***

# Коръән аятьләре, Рәсүлебез хәдисләре



Әбү Һөрәйрә сөйләве буенча, Пәйгамбәр салләллаһу аләйһи үә сәлләм әйткән:

"Баш тартучылардан башка, барлык өммәтем дә Җәннәткә керәчәк", Сәхабәләр сорыйлар: "Ә кем соң баш тартачак?". Әйтә: "Кем миңа буйсына, шул Җәннәткә керәчәк, ә кем миңа буйсынмый, шул баш тартачак" (Бохари).

Шәйх Ибн Бәәзнең шәрхеннән кыскача өзек:

"Хәдиснең мәгънәсе - Пәйгамбәр салләллаһу аләйһи үә сәлләмгә буйсынучы һәм аның юлыннан баручылар Җәннәткә керәчәк, ә кем аңа буйсынмаса, шул баш тартачак. Рәсүл салләллаһу галәйһи үәссәләмгә буйсынучы Аллаһыны берли (ягъни Аңа гына гыйбадәт кыла), Шәригатьтә нык тора, намазларын үти, зәкәтен бирә, Рамазан уразасын тота һәм ата-анасына ихтирам, кадер-хөрмәт күрсәтә. Аллаһ Тәгалә хәрам иткән нәрсәләрдән- зина, исерткечләр һ.б. үзен тыя.

Һәм шул кеше Җәннәткә керәчәк..."

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл әүүәл-Йомадиәл ахыр 2012 миләди йыл 1433 һижри йыл.**

| Йомадиәл-әүүәл, Йомадиәл-ахыр | Аҙна көндәре | Март, Апрель | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығы | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Шәмбе | 16 | 7.00 | 8.30 | 14.30 | 18.44 | 20.20 | 21.50 |
| 5 | Йәкшәмбе | 17 | 6.58 | 8.28 | 14.30 | 18.46 | 20.22 | 21.52 |
| 6 | Дүшәмбе | 18 | 6.55 | 8.25 | 14.30 | 18.48 | 20.24 | 21.54 |
| 7 | Шишәмбе | 19 | 6.53 | 8.23 | 14.30 | 18.50 | 20.25 | 21.55 |
| 8 | Шаршамбы | 20 | 6.50 | 8.20 | 14.30 | 18.52 | 20.27 | 21.57 |
| 9 | Кесе йома | 21 | 6.48 | 8.18 | 14.30 | 18.54 | 20.29 | 21.59 |
| 10 | Йома | 22 | 6.45 | 8.15 | 14.30 | 18.55 | 20.31 | 22.01 |
| 11 | Шәмбе | 23 | 6.43 | 8.13 | 14.30 | 18.57 | 20.33 | 22.03 |
| 12 | Йәкшәмбе | 24 | 6.40 | 8.10 | 14.30 | 18.59 | 20.35 | 22.05 |
| 13 | Дүшәмбе | 25 | 6.38 | 8.08 | 14.30 | 19.01 | 20.37 | 22.07 |
| 14 | Шишәмбе | 26 | 6.35 | 8.05 | 14.30 | 19.03 | 20.39 | 22.09 |
| 15 | Шаршамбы | 27 | 6.33 | 8.03 | 14.30 | 19.05 | 20.41 | 22.11 |
| 16 | Кесе йома | 28 | 6.30 | 8.00 | 14.30 | 19.07 | 20.43 | 22.13 |
| 17 | Йома | 29 | 6.27 | 7.57 | 14.30 | 19.09 | 20.45 | 22.15 |
| 18 | Шәмбе | 30 | 6.25 | 7.55 | 14.30 | 19.11 | 20.47 | 22.17 |
| 19 | Йәкшәмбе | 31 | 6.23 | 7.53 | 14.30 | 19.13 | 20.49 | 22.19 |
| 20 | Дүшәмбе | 1 | 6.20 | 7.50 | 14.30 | 19.15 | 20.51 | 22.21 |
| 21 | Шишәмбе | 2 | 6.17 | 7.47 | 14.30 | 19.17 | 20.53 | 22.23 |
| 22 | Шаршамбы | 3 | 6.15 | 7.45 | 14.30 | 19.19 | 20.54 | 22.24 |
| 23 | Кесе йома | 4 | 6.12 | 7.42 | 14.30 | 19.21 | 20.56 | 22.26 |
| 24 | Йома | 5 | 6.10 | 7.40 | 14.30 | 19.23 | 20.58 | 22.28 |
| 25 | Шәмбе | 6 | 6.07 | 7.37 | 14.30 | 19.24 | 21.00 | 22.30 |
| 26 | Йәкшәмбе | 7 | 6.05 | 7.35 | 14.30 | 19.26 | 21.02 | 22.32 |
| 27 | Дүшәмбе | 8 | 6.02 | 7.32 | 14.30 | 19.28 | 21.04 | 22.34 |
| 28 | Шишәмбе | 9 | 6.00 | 7.30 | 14.30 | 19.30 | 21.06 | 22.36 |
| 29 | Шаршамбы | 10 | 5.58 | 7.28 | 14.30 | 19.32 | 21.082 | 22.38 |
| 1 | Кесе йома | 11 | 5.55 | 7.25 | 14.30 | 19.34 | 1.10 | 22.40 |
| 2 | Йома | 12 | 5.53 | 7.23 | 14.30 | 19.36 | 21.12 | 22.42 |
| 3 | Шәмбе | 13 | 5.50 | 7.20 | 14.30 | 19.38 | 21.14 | 22.44 |
| 4 | Йәкшәмбе | 14 | 5.48 | 7.18 | 14.30 | 19.40 | 21.16 | 22.46 |
| 5 | Дүшәмбе | 15 | 5.45 | 7.15 | 14.30 | 19.42 | 21.18 | 22.48 |

# ХАТЫН-КЫЗ МАТУРЛЫГЫ

Бер күренекле рус язучысы: "Кешедә барысы да - йөзе дә, өс киеме дә, күңеле дә гүзәл булырга тиеш", - дигән. Бу гыйбарә әлеге көндә дә үз әһәмиятен югалтмаган һәм тулысынча ислам динендә чагылыш таба.

Исламда кеше эчке дөньясының матурлыгы белән генә чикләнмичә, киеме һәм тәненең пөхтәлеге, матурлыгы хакында да кайгыртырга тиеш. "Аллаһы Тәгалә матур һәм матурлыкны ярата" диелә бер хәдистә.

Әмма кайчакта кешенең эчке һәм тышкы кыяфәтктә булган омтылышы бергә тәңгәл килеп бетми. Кемнәрдер эчке матурлыкны үзенә мөһимрәк дип саный һәм өс-башына артык игътибар итми. Икенчеләре, киресенчә, үз образлары өстендә артык эшләп, аны баш ию объектына әверелдерелә, ә рухы хакында, әлбәттә, ул оныта.

Тышкы һәм эчке матурлыкны бер-берсеннән аерым карап булмый. Бу кешенең сыйфатын билгели торган категорияләрнең табигате бер түгел, шунлыктан да аларның һәрберсе үзенчә кыйммәт нык кабатланмас.

Күркәм холыклы кеше, гадәттә, түземле, тыйнак һәм әхлаклы була. Ә тышкы кыяфәт исә үз чиратында, гамәли кыйммәткә ия. Матур һәм чиста киемнән булган кеше башкаларда үзе хакында һәм дине хакында уңай образ тудыра. Бу хакта Абдул-Ахвәс әл-Джашами бер хәдистә:



"Бер тапкыр Пәйгамбәребез (с.г.в.) мине иске һәм ертылып беткән киемдә күргәч, матьди хәләтем хакында кызыксынды. Мин үземнең хәлле икәнлегемне белдердем. "Синең нинди байлыгың бар?" - дип соргач, "Аллаһы Тәгалә биргән дөяләрем һәм сарыкларым бар", - дип әйттем. "Шулай булгач, күрсәт миңа аларны", - дип әйткән. (Тирмизи).

Тарихыбызда эчке һәм тышкы матурлыкка ия, безгә үрнәк булган Әбү Хөрәйраны алыйк. Ул бер яктан югары дәрәҗәле галим дә булган, заманча итеп затлы киенергә дә яраткан. Билгеле булганча, ул озын сакал йөрткән, чалма һәм сандалида булган. Башкалардан сүз осталыгы, исле май кулланырга яратканлыгы белән аерылып торган.

Шулай булгач, ислам дине үз-үзеңне пөхтә итеп тотарга, бизәргә, хәләңә карата затлы итеп киенергә киңәш итә. шулай ук матур киендем, дип һаваланып йөрү дөрес булмас. Һәр эштә сак һәм уртача булу шарт.

Исламда аеруча хатын-кыз матурлыгына игътибар бирелә. Хатын-кыз чибәрлеге әнҗе бөртегедәй ят күзләрдән саклана һәм тулысынча гаилә эчендә ачыла. Аның гүзәллеге тормыш иптәшен сокландыра, шатландыра. Матур киенеп, күтәренке кәеф белән иреңне каршылау - хатын-кызның төп бурычы булып тора.